| | |
|---|---|
| БАЛТАСИНСКИЙ РАЙОННЫЙ<br>ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>БАЛТАЧ РАЙОН<br>БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«25» 09 2020 г. № 283

**Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитетының «Мәктәп автобус маршрутларын эксплуатацияләүне дәвам итү турында"гы 31.08.2020 ел, № 269/1 карарына үзгәрешләр кертү турында»**

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында мәктәп автобусларыннан нәтиҗәле файдалану чаралары турында» 2006 елның 3 августындагы 400 номерлы карары нигезендә, Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы белем бирү учреждениеләре укучыларын имин һәм өзлексез транспорт белән китерүне тәэмин итү максатларында, Татарстан Республикасы Балтач районы башкарма комитеты карар бирә:

1. Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитетының «Мәктәп автобус маршрутларын эксплуатацияләүне дәвам итү турында» 31.08.2020 ел, № 269/1 карарының 1 пунктына, укучыларны 21 нче автобус маршруты паспорты буенча йөртүче маршрутның хәрәкәтен түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәрешләр кертергә:

- Чепья-Әтнә – Пижмара-Чипья-Янгурчи-Арбор-Чипья (Чепья т.п.).

2. Әлеге карарны pravo.tatarstan.ru «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы»нда бастырып чыгарырга һәм Балтач муниципаль районының baltasi.tatarstan.ru рәсми сайтында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты җитәкчесе урынбасарына (социаль мәсьәләләр буенча) йөкләргә.

Җитәкче А.Ф. Хәйретдинов